| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**07.10.2024** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3822** |
|---|---|---|

Зеленодольск муниципаль районы тарафыннан капитал кертемне саклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

Инвестиция эшчәнлеген үстерү өчен уңай шартлар тудыру максатларында, «Россия Федерациясендә капитал кертемне саклау һәм кызыксындыру турында» 2020 елның 01 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 4 ст. 8 өлеше нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы тарафыннан капитал кертемне саклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru)рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисадый үсеш буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.С. Бауэрга йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
22024 елның 07 октябрендәге
3822 номерлы карарына
кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАРАФЫННАН КАПИТАЛ КЕРТЕМНӘРНЕ САКЛАУ ҺӘМ КЫЗЫКСЫНДЫРУ ТУРЫНДА КИЛЕШҮЛӘР ТӨЗҮ ШАРТЛАРЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ ХАКЫНДАГЫ НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми сораулар

1.1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы тарафыннан капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе турында әлеге нигезләмә (алга таба -Нигеезләмә) «Россия Федерациясендә капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 8 өлеше (алга таба - Федераль закон) нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы тарафыннан капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү шартларын һәм тәртибен билгели. Нигезләмә капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турындагы килешү нигезендә инвестицияләрне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1.2. Капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешүләр төзү өлкәсендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының вәкаләтле структур бүлекчәсе булып Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе бүлеге (алга таба – ТОСЭР бүлеге) тора.

1.3. Капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешүне төзүгә, үзгәртүгә һәм өзүгә бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә карата, шулай ук күрсәтелгән килешү буенча йөкләмәләрне үтәүгә бәйле рәвештә, Федераль законда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, граждан законнары кагыйдәләре кулланыла.

1.4. Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр һәм терминнар күрсәтелгән хокук мөнәсәбәтләрен регламентлаштыручы РФ законнарындагы мәгънәләрендә кулланыла.

## 2. Капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турындагы килешүнең предметы һәм шартлары

2.1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турындагы килешүнең бер ягы булып тора, әгәр Татарстан Республикасы территориясендә тиешле инвестиция проекты гамәлгә ашырылса, Татарстан Республикасы бер үк вакытта мондый килешүнең ягы була.

2.2. Килешү Россия юридик заты белән төзелә, ул түбәндәге таләпләрне канәгатьләндерә (алга таба мөрәҗәгать итүче):

а) мөрәҗәгать итүче Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 8 пунктында билгеләнгән проектны гамәлгә ашыручы оешма билгеләренә җавап бирә;

б) мөрәҗәгать итүче бетерелү процессында булмый;

в) мөрәҗәгать итүчегә карата Россия Федерациясе законнары нигезендә бөлгенлек (банкротлык) турындагы эш буенча җитештерү кузгатылмаган;

г) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, башка түләүләр, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычы булмаска тиеш.

2.3. Капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турындагы килешү Россия икътисадының бер тармагында яңа инвестицион проектны гамәлгә ашыруны күздә тоту шарты белән мондый килешү проектны гамәлгә ашыручы оешма белән төзелә, түбәндәге өлкәләрдән һәм эшчәнлек төрләреннән тыш:

1) уен бизнесы;

2) тәмәке эшләнмәләрен, алкогольле продукцияне, сыек ягулыкны җитештерү (күмердән алынган сыек ягулыкка, шулай ук нефть чималын икенчел эшкәртү җайланмаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлек нигезендә чикләүләр кулланылмый);

3) чи нефть һәм табигый газ, шул исәптән иярчен нефть газы чыгару (табигый газны сыекландыру буенча инвестиция проектларына карата чикләүләр кулланылмый);

4) күпләп һәм ваклап сату;

5) Россия Федерациясе Үзәк банкына буйсынучы финанс оешмалары эшчәнлеге (инвестиция проектын финанслау максатларында кыйммәтле кәгазьләр чыгару очракларына карата чикләүләр кулланылмый);

6) административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар) (аэровокзаллардан (терминаллардан) тыш), шулай ук күп фатирлы йортлар, торак йортлар булдыру (төзү) йә реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү(территорияне комплекслы үстерү турындагы шартнамә нигезендә мондый йортлар төзүдән тыш).

2.4. Проектны гамәлгә ашыручы оешмага карата Федераль законның 9 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән, капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешү төзелгән инвестиция проектын гамәлгә ашыруга бәйле эшкуарлык һәм (яисә) башка эшчәнлек алып бару шартларын мондый килешү төзелгән вакытка билгеләнгән шартлар белән чагыштырганда начарайта торган (стабилизацион төзәтмә) һәм Федераль законның 9 статьясындагы 7.1 өлеше нигезендә дәүләт хакимияте органнары тарафыннан расланган исемлекләр нигезендә проектны гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан тапшырылган актлар (карарлар) кулланылмый. Эшкуарлык һәм (яисә) башка эшчәнлек алып баруның иң начар шартлары дип түбәндәге актлар (карарлар) таныла,алар:

1) инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле процедураларны гамәлгә ашыру срокларын арттыра;

2) инвестиция проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле процедуралар санын арттыра;

3) инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында түләнә торган проектны гамәлгә ашыручы оешмадан алына торган күләмне арттыра;

4) инвестиция проектын гамәлгә ашыру шартларына карата өстәмә таләпләр билгели, шул исәптән өстәмә документлар бирү турындагы таләпләр;

5) инвестиция проектын гамәлгә ашыруга комачаулаучы өстәмә тыюлар билгели.

Шул ук вакытта проектны гамәлгә ашыручы оешма Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетыннан инвестиция проектын гамәлгә ашырганда мондый актларның (карарларның) кулланылмавын таләп итәргә хокуклы.

2.5. Гавами-хокукый берәмлекнең әлеге Нигезләмәнең 2.4 пунктында каралган критерийларга туры килә торган актлары (карарлары), түбәндә күрсәтелгән :

1) Федераль законның 9 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктында, капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турындагы килешүдә каралган срок дәвамында кулланылмый;

2) Федераль законның 9 статьясындагы 3 өлешенең 3 пунктында, шушы чорда капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешү гамәлдә булса, алар үз көченә кергән көннән алып өч ел дәвамында кулланылмый;

3) Федераль законның 9 статьясындагы 3 өлешенең 2 пунктында Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 1 һәм 2 пунктларында, 15 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү срогына тигез булган капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турындагы килешүдә каралган срок яисә Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктының «а» пунктчасында каралган шартнамәнең гамәлдә булу срогы дәвамында кулланылмый;

4) Федераль законның 9 статьясындагы 3 өлешенең 4 һәм 5 пунктларында, капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешү шушы чорда гамәлдә булган очракта, түләү күләмен билгеләгәндә кулланыла торган түләү (җыем) ставкалары инфляция күрсәткечено тигез күләмдә арттырылган очраклардан тыш, алар үз көченә кергән көннән алып өч ел дәвамында кулланылмый.

2.6. Капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешү төзегән Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты инвестиция проектын гамәлгә ашыру йөкләмәләрен яисә инвестиция һәм (яисә) хуҗалык эшчәнлеген алып баруга бәйле, шул исәптән проектны гамәлгә ашыручы оешма белән берлектә, нинди дә булса башка йөкләмәләрне үз өстенә алмый.

## 3. Капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешү төзү тәртибе

3.1. Килешү төзүгә муниципаль берәмлекнең ризалыгын алу максатларында «Россия Федерациясендә кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында» 69-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 7 өлешенең 3 пункты, 8 статьясындагы 9 өлешенең 5 пункты нигезендә проектны гамәлгә ашыручы оешма билгеләренә җавап бирүче Россия юридик заты (алга таба – мөрәҗәгать итүче) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Башкарма комитет җитәкчесе исеменә түбәндәге документларны җибәрә:

1) Килешүдә катнашуга бәйле рәвештә муниципаль берәмлектә барлыкка килә торган йөкләмәләрне үтәүгә һәм Килешү төзүгә, шул исәптән федераль законның 9 статьясы нигезендә муниципаль берәмлек актларын (карарларын) проектны гамәлгә ашыручы оешмага карата тотрыкландыру буенча муниципаль берәмлекнең ризалыгын алу турында гариза;

2) бәяләмәгә фаразланучы Федераль законның 4 статьясы нигезендә Килешү проекты;

3) Федераль законның 7 статьясындагы 7 өлеше нигезендә документлар һәм материаллар.

3.1.1. Гариза һәм аңа кушылып бирелә торган документлар «Капиталовложения» дәүләт мәгълүмат системасы сервисының шәхси кабинеты аша тапшырылырга мөмкин. Гариза шәхси кабинет аша бирелгән очракта гариза электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, кушып бирелә торган документлар – электрон имза белән имзаланган электрон документлар һәм

(яисә) электрон имза белән таныкланган кәгазь документларның электрон рәвешләре формасында тутырыла. Кәгазь документның электрон образы форматына карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

3.1.2. Мөрәҗәгать итүче капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешү төзегән вакытка кадәр яисә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан кире кагылган вакытка кадәр, аның белән капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турында килешү төзүдә түбәндәгеләргә хокуклы:

1) гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны гаризаны кире алу турында хәбәрнамә җибәрү яисә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып мондый хәбәрнамә бирү юлы белән кире алырга;

2) гаризага һәм Федераль законның 7 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән аңа кушып бирелә торган документларга үзгәрешләр кертергә, бу чакта гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны карау срогы 30 эш көненнән дә артмаган вакытка озайтыла.

Мөрәҗәгать итүче Федераль законның 7 статьясындагы 9.1 өлеше нигезендә гаризаны кире алган очракта, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты мөрәҗәгать итүчегә гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны Федераль законның 7 статьясындагы 9.1 өлешендә күрсәтелгән гаризаны кире алу турында хәбәрнамә алынганнан соң 15 эш көне эчендә кире кайтара.

3.2. ТОСЭР бүлеге мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны, документлар кергән көннән башлап, 45 эш көне эчендә карый.

3.3. ТОСЭР бүлеге бәяләмә бирү турында рәсми мөрәҗәгатьне күчермәсе белән бергә , шулай ук төзүгә күздә тотыла торган Килешү проектын кушып, мөрәҗәгать итүченең документлары кергән көннән алып 5 эш көненнән дә артмаган срокта түбәндәгеләргә җибәрә:

1) Зеленодольск муниципаль районының муниципаль милкендәге Килешүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле җир кишәрлекләрен , Килешүне гамәлгә ашыру өчен кирәкле күчемсез мөлкәт объектларын, хокукый режимга бәйле мәсьәләләр өлешендә , Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына

2) Килешү объектының территориаль планлаштыру, шәһәр төзелешен зоналаштыру документларына, шулай ук территорияне планлаштыру документларына туры килүе өлешендә Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсенә ;

3) Вәкаләтләре Инвестицион проект килешүе кысаларында гамәлгә ашырыла торган өлкәгә керүче органга.

3.4. Рәсми мөрәҗәгатьне карау йомгаклары буенча, рәсми мөрәҗәгать кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында күрсәтелгән бүлекләр ТОСЭР бүлегенә тиешле бәяләмәләр тапшыралар.

3.5. Тәкъдим ителгән мәгълүматны исәпкә алып, ТОСЭР бүлеге 5 эш көне эчендә Башкарма комитет Җитәкчесенә Килешүне төзү мөмкинлеге йә мөмкин булмавы турында бәяләмә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән документларның күчермәләрен әзерли һәм раслау өчен җибәрә.

3.6. 5 эш көне эчендә Башкарма комитет җитәкчесе әлеге Нигезләмәнең 3.5 пунктында күрсәтелгән бәяләмәне резолюция белән раслый.

3.7. Килешү проектын эшләп бетерү кирәклеге турында Башкарма комитет җитәкчесе карар кабул иткән очракта, ТОСЭР бүлеге,кисәтүләрне исәпкә алып, 5 эш көне эчендә Килешү проектын эшләп бетерә, шуннан соң эшләп бетерелгән Килешү проектын әлеге Нигезләмәнең 3.5 пунктында каралган тәртиптә Башкарма комитет Җитәкчесенә раслау өчен җибәрә.

3.8. Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан Килешү төзү турында карар кабул ителгән очракта, ТОСЭР бүлеге мондый карар кабул ителгән көннән алып 5

эш көне эчендә Башкарма комитетның Килешү төзүгә ризалык бирү турында карар проектын әзерли.

Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан карарга кул куйган көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча, ТОСЭР бүлеге аның күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

3.9. Килешүне төзү мөмкин булмау турында карар кабул ителгән очракта, ТОСЭР бүлеге мондый карар кабул ителгән көннән алып 5 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә, әлеге Нигезләмәнең 3.10 пунктында каралган нигезләрдә баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, кабул ителгән карар турында язмача хәбәр итә.

3.10. Килешүне төзүгә ризалык бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

1) гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар, шул исәптән Килешү проекты әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләргә туры килми;

2) гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртипне бозып бирелгән;

3) мөрәҗәгать итүче тарафыннан Федераль законның 6 статьясында билгеләнгән шартлар үтәлмәгән;

4) мөрәҗәгать итүче Россия юридик заты булмый яисә дәүләт (муниципаль) учреждениесе йә дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе булып тора;

5) инвестиция проекты яңа инвестиция проекты булып тормый;

6) мөрәҗәгать итүченең салымнар, җыемнар, таможня түләүләре, таможня органнарына йөкләнгән башка түләүләр, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары булу;

7) мөрәҗәгать итүче тарафыннан үзе турында дөрес булмаган мәгълүмат (юридик затларның бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләргә туры килми торган мәгълүмат) тапшырылган булу.

3.11. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны караганда, ТОСЭР бүлеге, Башкарма комитет белгечләрен җәлеп итеп, киңәшмәләр үткәрә, Килешүне гамәлгә ашыру ихтималы булган мәсьәләләр буенча кирәкле аңлатмалар алу максатында, тиешле органнар вәкаләтләре чикләрендә рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә.

3.12. Кирәк булганда, ТОСЭР бүлеге мөрәҗәгать итүчедән өстәмә материаллар һәм документлар соратып алырга, сөйләшүләр уздырырга, шул исәптән мөрәҗәгать итүче белән уртак киңәшмәләр рәвешендә дә.

3.13. Муниципаль берәмлек исеменнән капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турындагы килешү Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан имзалана һәм Федераль законның 7 статьясында каралган процедураларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча төзелә.

## 4. Йомгаклау нигезләмәләре

4.1. Капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турындагы килешү шартларын бозган өчен җаваплылык турындагы нигезләмәләр Федераль законның 12 статьясында билгеләнгән.

4.2. Капитал кертемнәрне саклау һәм кызыксындыру турындагы килешү буенча бәхәсләрне карау тәртибе Федераль законның 13 статьясында билгеләнгән

4.3. Килешүләргә бәйле нигезләмәләр Федераль законның 14 статьясында билгеләнгән.